КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 724

2020 елга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары нигезендә билгеләнгән айлык акчалата түләүләрне һәм түләүләрнең башка төрләрен индексацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законының 4 – 8 статьяларында күздә тотылган айлык акчалата түләүләрне һәм түләүләрнең башка төрләрен индексацияләү коэффициентын 1,038 күләмендә;

айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре күләмнәрен кушымта нигезендә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бу карарның 1 нче пунктындагы өченче абзацта күздә тотылган айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре күләмнәрен билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне аңлату эшен үткәрергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 август, 724 нче
карарына кушымта

**Айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре күләмнәре**

| Түләү төре | Түләү күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Айлык акчалата түләү:<br>пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты хакында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яисә алар 2018 елның 31 декабренә Федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына; | 505,0 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге, 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 нче пунктта каралмаган башка нигезләр буенча пенсияләр ала торган яисә 60 һәм 55 яшькә җиткән (ир-атлар һәм хатын-кызлар) эш (хезмәт) өчен гомерлек түләү ала торган, мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына; | 505,0 |
| «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты хакында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә Федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затларга; | 505,0 |

| 1 | 2 |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажы булган, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5.1 статьясындагы 1 – 3 нче пунктларда каралмаган башка нигезләр буенча пенсияләр ала торган яисә 60 һәм 55 яшькә җиткәннәр (туры килү буенча ир-атлар һәм хатын-кызлар) эш (хезмәт) өчен гомерлек түләү ала торган затларга;<br>1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда кимендә алты ай тылда эшләгән затларга (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чоры керми); Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затларга;<br>акланган гражданнарга;<br>сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган граждан-нарга;<br>опекага (попечительлеккә), башка гаиләләргә тәрбиягә бирелгән ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга:<br>мәктәпкәчә яшьтәге балаларга<br>мәктәп балаларына | 505,0<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>754,0<br><br><br><br><br>754,0<br>632,0<br><br><br><br><br>8 997,0<br>10 375,0 |
| Транспортта йөрүгә субсидия:<br>ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга;<br>18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән булган, шул исәптән тәрбиягә алган гаиләләрдән, гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларга – алар укып бетергәнче, әмма 18 яшькә җиткәннән соң түгел | <br>307,0<br><br><br><br>307,0 |
| <br>18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән булган, шул исәптән тәрбиягә алган гаиләләрдән, 6 яшькә кадәрге баласы өчен дару чаралары сатып алуга субсидия | 136,0 |
| Уртача айлык керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 | |

| 1 | 2 |
|---|---|
| елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган балалы гаиләләргә айлык пособие:<br>16 яшькәчә балага (гомуми белем бирү оешмасында белем алучыга – ул укып бетергәнче, әмма 18 яшькә җиткәннән соң түгел);<br>ялгыз ана баласына;<br>ата-аналары алимент түләүдән баш тарткан балага яки Россия Федерациясе законнарында каралган башка очракларда алиментлар түләттереп булмаса;<br>сержант, старшина, солдат һәм матрос сыйфатында хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр баласына, шулай ук хәрби хезмәтне үтү турында контракт төзегәнче атасы хәрби һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениесендә булган балага | <br><br><br><br>334,0<br><br><br>882,0<br>499,0<br><br><br><br>499,0 |
| Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән пенсионерларга, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (туры килү буенча ир-атлар һәм хатын-кызлар), күрсәтелгән федераль законнарда каралган, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән гражданнарга (туры килү бенча ир-атлар һәм хатын-кызлар) пенсия билгеләү шартларына туры килә торган Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары буенча 2018 елның 31 декабренә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү:<br>мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган пенсионерларга;<br>мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000,01 сумнан 25 000 сумга кадәр тәшкил иткән пенсионерларга | <br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>505,0<br><br>180,0 |
| Гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны белем алу чорында туклану белән тәэмин итү | 7,7<br>(көн саен) |

_______________